## “Сүз” берәмлеге туры мәгънәдә һәм күчерелмә мәгънәдә кулланылган мәкальләр

Дөньяда телсез яки җырсыз-моңсыз халык булмаган кебек, мәкальсез халык та юктыр. Һәрбер халык сүз арасында мәкальләр кыстырырга ярата, үз телен аның белән бизи, төзи. Һәркайда, һәр халыкта үз мәкальләренә хөрмәт бар, аларга ышану, таяну бар. Безнең халыкта да шундый ук хәл: татар сөйләшкәндә сүз арасында, урынына карап, фикерне куәтләү өчен кыска гына һәм килешле генә итеп, хикмәтле бер мәкаль әйтеп куя. Ул моны әйтеп җибәргәнен кайчак үзе дә сизми кала. Шуның белән безнең халкыбыз арасында да саны әлегә хәтле беленмәгән күп төрле мәкальләр йөри.

Мәкальләрне мәгънә ягыннан ике төркемгә бүлеп була: алар я туры мәгънәсендә, я читләтеп, кинаяя белән әйтеләләр.

Сүз берәмлеге туры мәгънәдә_кулланылган мәкальләр, күбесенчә, үгет-киңәш бирү, яки, чынбарлыктан алынган мөһим бер күзәтмә, кагыйдә урынында әйтеләләр: *Кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә(III, 344)*. Мондыйларны беренчел, ягъни турыдан-туры мәгънәсендә әйтелгән дияргә туры килә. Лексик яктан һәр сүз билгеле бер мәгънәгә ия булу белән характерлана. Ә кинаяле мәкальләр чынбарлыктан алынган берәр шигъри мисал төсендә читләтеп әйтеләләр. Болары – икенчел, ягъни читләтелгән мәгънәле мәкальләр. Мәкальләрдә сүзне һәрвакыт үлчәп сөйләүгә ишарә бар, юкка-барга күп сөйләмәүчеләр татар халкында элек-электән хөрмәт ителеп килгәннәр. Өлкәннәр тарафыннан акыллы сүзләр генә сөйләргә киңәш ителә: *Аз сүз – уз сүз, күп сүз – чүп сүз (V, 441); Аз сүздән мәгънә чыгар, күп сүздән бәла чыгар(V,441); Акыллы сүз алтыннан кыйбат (V,442); Сүз сөйли белсәң ирмәк, сөйли белмәсәң, имгәк (V,448). Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы (V,449).* Ә русларда түбәндәге мәкальләр кулланыла: *Лишнее слово в досаду вводит(VI, 316); За худые слова слепнит и и голова (VI,315)*

Кызу-кызу әңгәмә корганда кеше үзенең авызынннан ни чыкканын да абайлап өлгермәскә мөмкин, моны практика күрсәтә.

Һәм бу кешеләр арасында бозылышуга китерә. Сүзне нинди дә булса предмет белән чагыштыру шулай ук киң таралган: *Әйткән сүз – кискән икмәк: кире ябыштырып булмый (V,453);* Сүзне әйтсәң дә дөресен сөйләп, аны инде икенче төрле сөйләргә калдырмаска кирәк дигәндә *Сүзне әйтмә, әйтсәң – кайтма (V,448)*дигән мәкальне кулланалар. Ә русларда *Слово сказал, так на нем хоть терем клади (VI, 319)* мәкален мисалга китерә алабыз. Берәр сөйләшү вакытында иптәшең синең йөзеңә турысын бәреп әйтсә, син инде *“Бәрәңгедә сөяк юк, туры сүзгә җавап юк”( V,443)* дип җөпләп кую ягында торасың. Әлбәттә, “Туры әйткән туганына ярамаган” дигән әйтем халык арасында киң таралыш алган, ләкин туры, дөрес сүзнең ахыры һәрвакыт яхшылык белән тәмамланачак. Чөнки туры сүзне ишетү беренче мәлгә авыр булса да, кеше аннары үзенә нәтиҗә чыгарып, алга таба шулай эшләргә кирәклегенә төшенә: *Туры сүз ачы булыр, ахыры яхшы булыр(III, 446); Туры сүз кылычтан үткен (V,449); Туры сүз, ачы булса да, киләчәккә файда (III,447); Туры сүз туганына ярамыйIII; Туры сүз, ачы булса да, киләчәккә файда (III 447); Туры сүзгә ант кирәкми (III,447); Туры сүздә оят юк (III,447); Туры сүзле адәмне яхшы кешеләр дошман күрерләр (III, 447); Ялган сүзгә савап юк, туры сүзгә җавап юк (II, 452)I; Үзең кыек утырсаң да, сүзең туры булсын (III, 451); Сүз сөйләсәң, сүзең дөрес булсын (III,451); Кеше ышанмаслык сүзне дөрес булса да сөйләмә(III,451).* Әлеге мәкальләрдән соң русларның бкерничә мәкален дә мисалга китерү уңышлы булыр: *От одних слов толку мало (V,318); Слово крепче печати (V,319); Яркое слово смужает сердце (VI, 320); Не давит слова – крепись, а давит – держись(VI, 317).* Кеше үзенең файдалы хезмәтләре белән генә дан ала ала, шөһрәт казана. Юкка гына *Агачны – яфрак, кешене – хезмәт бизи* димәгәннәр. Һәм бу әйтемгә аваздаш алдагы мәкальне мисалга китерергә мөмкин: *Сүз башка, эш башка (III,442); Сүздән эшкә кү (III, 442).* Сүз белән артык мактанган

кешеләр бар, шуңа күрә сүз белән әллә ниләр майтарып була ул диләр. Ләкин эшләгән эшең күрсәтерлек булмаганда, сүз белән мактану көлкегә генә китерә: *Сүз белән ботка пешсә, бер казан май миннән(III, 448).Сүзең белән эшең бер булсын (III, 442); Сүз кирәкми, эш кирәк (III, 442); Сүз күп җирдә эш аз була (III,442)* бу мәкальләргә охшашлы рус мәкален мисалга китерә алабыз*: Где много слов, там мало правды (VI,313); Эштә сүзгә мавыкма (III, 446); Эшләгән эшкә үкенү юк (III 465), Сөйләгән сүзгә үкенү бар(III,466)* – кеше бер эшне эшләгән булса, җавабын да, җәзасын да үзенә йөкли, әмма бер эшне эшләмәгән хәлдә сөйләнү аркасында үзенә яки кешегә зарар килсә, монда үкенү бар.

Күп кенә мәкальләр турыдан-туры әйтелү мәгънәсен генә белдермиләр. Өстән караганда, бу мәкаль нинди дә булса фикерне яклап киңәш бирә дип уйлыйсың, ә ул аны сиңа ирония белән әйтеп, киресенчә аңларга кирәк икәнен үз сизгерлегеңә тапшырган булып чыга. Кыскасы, мәкальләрне куллана белү яки аңлауда акыл белән эш итәргә кирәк. Шул рәвешле мәкаль үзе, бик кечкенә булса да, күпьяклы, үзенчәлекле һәм хикмәтле нәрсә. “Сүз” берәмлеге кучерелмә мәгънәдә кулланылган мәкальләрдә дә күрергә мөмкин: *Авызың кыек булса да, сүзең туры булсын (III, 445)* – хәбәрне белдерә*; Мең сүз сөйләгәнче бер сүз сөйлә ул да туры булсын(III,446)* – эшне белдерә*; Телнең зиннәте туры сүз (III, 446)* – хәбәрне белдерә*; Туры сүз алланы шатландырса да, адәмнең ачуын китерер (III, 446)* – хәбәрне белдерә*; Туры сүз бер булса да, һәркемгә җитәр (III. 446)*- хәбәрне белдерә*; Туры сүз күзне тишә (V,449)* – процессны белдерә; *Туры сүз кыектан әйтсә дә, туры тия (III, 446); Туры сүз таш кисә (III, 447)* – процессны белдерә. Яхшы сүзнең һәрвакыт кеше өчен хикмәтле, мәгънәле икәнлеген тоярга, сизәргә була, аның антонимы начар сүзнең бөтен начарлык эшләргә дә сәләтле икәнлеге ачык күренә: Алдагы мәкальләр хәбәрне белдерәләр: *Яхшы сүз балдан*

*татлы (III, 444)*; *Яхшы сүз белән елан өненнән чыгар, яман сүз белән пычак кыныннан чыгар (III, 444); Яхшы сүз бер генә булса да, бар кешегә җитәр (III444 – процессны белдерә); Яхшы сүз таш эретә, яман сүз баш черетә (III,445); Яхшы сүз ялар, яман сүз талар (III, 445); Сүзне сүзгә тоташтырсаң ип булыр, ил бозылса, тугрыдан угры күп булыр (III, 446); Яхшы сүз бер генә булса да, бар кешегә җитәр(III, 446); Яманның сүзен сөйләмә, явызның давын даулама(III. 447); Бер яхшы сүз мең күңелнең җәрәхәтен төзәтә (III, 447).* Рус теленннән *Доброе слово лучше мягкого пирога (VI,314); Доброе слово человеку что дождь в засуху (VI,314); И доброе слово не уймет злого (VI,315); Красное словце – не ложь (VI,316); От доброго слова язык не сохнет (VI,318); Доброе слово сказать – посошок в руки дать (VI,314); Доброе слово железные ворота отопрет (VI,314)* дигән мәкальләрне мисалга китерә алабыз. Кешеләр арасында низаг килеп чыгуга иң беренче булып авыздан чыккан сүз гаепле: *Тау белән ташны су боза, кеше белән кешене сүз боза (V,449)*- хәбәрне белдерә һәм бу мәкальгә охшаш мәкальне рус теленнән дә китерә алабыз: *Ветры горы разрушают – слово народы подымает (VI,313); Из-за одного слова до вечная ссора (VI,315).* Тормышта инде олы тәҗрибә туплаган кешеләр яшьләргә кеше сүзенә артык ышанмаска киңәш итәләр: *Кеше сүзе, таш ярмаса да, баш ярыр (V,445) – процессны белдерә ; Кеше сүзе белән коега капланырсың (V,445); Кеше сүзе кеше үтерә (V,445); Хоть слово не обух, а от него люди гибнут (VI,320).* Болай сүзгә-сүз туры килү очракларыннан тыш, төрле халыкларның мәкальләре арасында идея якынлыгы, мәгънә охшашлыгы тагын да күбрәк күзәтелә. Элек-электән үк сөйләм телендә әйтсәң бер яхшы, әйтмәсәң мең яхшы дигән әйтем йөри. Рус телендә бу әйтемгә охшаш *Сказанное слово – серебряное, а несказанное – золотое (VI 448).*

Югарыда китерелгән татар мәкальләре бездә дә руслар белән шундый ук охшашлык һәм уртаклык барлыгын күрсәтәләр.

Мәкальләрнең картотекасын туплаганда шуңа игътибар иттек: “сүз” компонентлы мәкальләр күбрәк күчерелмә мәгънәсендә кулланылалар. Тема ягыннан да шулай. Берсендә берләре бар яки баерак булса, икенчесендә алары булмас яки аз әһәмият бирелгән була. Бу нәрсә халыкларда тормышның, зәвыкларның төрле-төрле булуына бәйләнгән. “Сүз” компонентлы мәкальләр татар телендә дә, рус телендә дә күчерелмә мәгънәдә күбрәк икәнлеген расладык; “Сүз” берәмлеге күчерелмә мәгънәдә кулланылган мәкальләр рус мәкальләре белән чагыштырганда күбрәк; сүзләрнең күпмәгънәлелеге кешеләрне зур мәшәкатьтән коткара. Һәрбер аерым предмет, аерым төшенчә өчен, аерым сүз булса, аралашу өчен ул бик авыр булыр иде; “Сүз” берәмлеге мәкальләрдә күбрәк- хәбәр, икенче урында – процесс белдерә; мәгънә ягыннан чагыштырганда татар мәкальләре белән рус мәкальләре арасында охшашлык һәм уртаклык барлыгын күрдек.

## Чыганаклар


I. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре / Н. Исәнбәт.- Казан: Татар. кит. нәшр., Т.1. 1959.- 913 б.

II. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре / Н. Исәнбәт.- Казан: Татар. кит. нәшр., Т.2. – 1963.- 959 б.

III. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре / Н. Исәнбәт.- Казан: Татар. кит. нәшр., Т.3. 1967.- 1013б.

IV Мәхмүтов Х. Татар халкының афористик иҗаты / Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / Х.Ш.Мәхмүтов.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.- 173 б.